ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ТИМОШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАРЫ

№ 5 01.11. 2022ел

«Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино
авыл җирлегенең Иске Тимошкино торак пунктында
гражданнарның үзара салымнарын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегендә үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 10 ноябрендә 8 сәгать 30 минутка гражданнар җыенын билгеләргә.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елда Аксубай муниципаль районының Иске Тимошкино авыл җирлеге Иске Тимошкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә , моннан тыш, 1 төркем инвалидлардан, БВС ветераннарыннан, Украинадагы махсус операциядә катнашучы гражданнардан һәм аларның гаиләләреннән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала; Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы:

**1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

**- - кышкы чорда Иске Тимошкино авылы эчендәге юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, кардан чистарту);**

**- бистә эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, грунт һәм вак ташны салу һәм тигезләү, юлларны чокыр белән ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);**

2. **Каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**- контейнер мәйданчыкларын урнаштыру, (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

1. Торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы);

2. Күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3. Ритуал хезмәтләрен оештыру һәм күмү урыннарын тәртиптә тоту
- Иске Тимошкино зиратында агач һәм үсентеләр кисү килешүе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Аксубай районы Иске Тимошкино авылының Ленин урамы 27 нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында халык җыены үткәрергә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендә авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыелган урыннарда, стендларда һәм белдерү такталарында элену юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга кирәк.

5.Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы : П.А.Мулеева